**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛәЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Дүртенче чакырылышның унҗиденче утырышы**

**24.10.2022 ел** **№71** **Югары Кибәхуҗа авылы**

Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 18.05.2018 ел № 73 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен, рәис урынбасарларын, аудиторларын һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын, айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 18.05.2018 ел № 73 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына (алга таба текст буенча - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1 пунктта "11 163,0" санын "11 958,0" санына алмаштырырга;

1.2. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 18.05.2018 ел № 73 карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа исемнәре | Коэффициентлар |
|---|---|
| | 12 төркем |
| 1 | 2<br>(сум) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 16 390,0 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 11 959,0 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Югары Кибәхуҗа авыл
җирлеге башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов